**КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2016 ел, 3 октябрь № 708

г. Казань

Татарстан Республикасы ия булган җир асты байлыклары турында геологик мәгълүматны файдалану кагыйдәләрен раслау турында

«Җир асты байлыклары турында» 1992 елның 21 февралендәге 2395-1 нче Россия Федерациясе Законының 4 статьясындагы 4 пункт, «Җир асты байлыклары турында» 1992 елның 25 декабрендәге 1722-XII нче Татарстан Республикасы Законының 6 статьясындагы унберенче абзац нигезендә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Карарга теркәлгән Татарстан Республикасы ия булган җир асты байлыклары турында геологик мәгълүматны файдалану кагыйдәләрен расларга.

2. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Экология һәм табигый байлыклар министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры
вазыйфаларын башкаручы А.В.Песошин

F:\KARAR\2016\708.docx

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2016 ел, 3 октябрь, 708 нче карары белән расланды

Карарга теркәлгән Татарстан Республикасы ия булган җир асты байлыклары турында геологик мәгълүматны файдалану
кагыйдәләре

1. Әлеге Кагыйдәләр Татарстан Республикасы ия булган җир асты байлыклары турында геологик мәгълүматны файдалану тәртибен һәм шартларын билгели.

2. Татарстан Республикасы бюджеты һәм җирле бюджетлар акчасы исәбенә җир асты байлыкларыннан файдаланучылар алган җир асты байлыклары турында геологик мәгълүматка, шулай ук «Җир асты байлыклары турында» 1992 елның 21 февралендәге 2395-1 нче Россия Федерациясе Законының 27 статьясындагы ундүртенче өлештә күрсәтелгән вакытлар үткәннән соң үз акчасы исәбенә җир асты байлыкларыннан файдаланучылар алган җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары участокларына карата җир асты байлыклары турында геологик мәгълүматка ия булучы булып Татарстан Республикасы тора (алга таба – җир асты байлыклары турында геологик мәгълүмат).

3. Татарстан Республикасы исеменнән җир асты байлыклары турында геологик мәгълүмат иясе хокукларын Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең вәкаләтле башкарма органы – Татарстан Республикасы Экология һәм табигый байлыклар министрлыгы (алга таба – вәкаләтле орган) гамәлгә ашыра.

4. Физик һәм юридик затлар җир асты байлыклары турында геологик мәгълүматны файдаланучы була ала.

5. Физик һәм юридик затлар җир асты байлыклары турында геологик мәгълүматны җир асты байлыклары турында, мәгълүмат, мәгълүмат технологияләре хакында һәм мәгълүматны саклау турында, дәүләт сере һәм коммерция сере хакында, шулай ук җир асты байлыклары турында геологик мәгълүмат экспорты турында законнар нигезендә бары тик аны алганда күрсәтелгән максатлар өчен генә файдаланалар.

6. Җир асты байлыклары турында геологик мәгълүмат түбәндәге ысуллар белән бирелә:

1) гариза бирүчене аның эчтәлеге белән таныштыру юлы белән, өземтәләр һәм күчермәләр алу хокукы белән кәгазьдә;

2) гариза бирүчене электрон документлар һәм материаллар белән таныштыру юлы белән гариза бирүченең электрон мәгълүмат йөртү җайланмаларына күчерү өчен мәгълүмати документлар һәм материалларның электрон сурәтләрен эшләү хокукы белән электрон мәгълүмат йөртү җайланмаларында.

7. Җир асты байлыклары турында геологик мәгълүмат физик һәм юридик затларга (алга таба – гариза бирүчеләр) вәкаләтле органга җибәрелгән гариза нигезендә бирелә.

8. Гаризада түбәндәгеләр булырга тиеш:

1) гариза бирүче турында мәгълүматлар (физик затның фамилиясе, исеме, әтисе исеме (булганда), аның яшәү (тору) урыны адресы, физик затның шәхесен таныклаучы документ мәгълүматлары, аның телефоны номеры яисә юридик зат урнашкан урын адресы);

2) җир асты байлыклары турында геологик мәгълүматны алу максаты;

3) соратылган мәгълүмат исемлеге (соратылган мәгълүматның төрен һәм аны бирү рәвешен күрсәтеп);

4) көне, гариза бирүче имзасы, мөһер (юридик затлар өчен);

5) дәүләт серен тәшкил иткән белешмәләргә кертелгән мәгълүматны алу хокукын бирә торган документ реквизитлары – дәүләт серен тәшкил иткән белешмәләргә кертелгән җир асты байлыклары турында геологик мәгълүматны сорап мөрәҗәгать иткәндә.

9. Мәгълүмат бирү турында гаризаны теркәгәннән соң 20 эш көне эчендә вәкаләтле орган гариза бирүче адресына җир асты байлыклары турында геологик мәгълүмат белән танышу яки җир асты байлыклары турында геологик мәгълүматны үз эченә алган документлар һәм материаллар күчермәләрен алу өчен вакыты һәм урыны турында яисә җир асты байлыклары турында геологик мәгълүмат бирүдән баш тарту хакында белдерү кәгазе җибәрә.

10. Җир асты байлыклары турында геологик мәгълүмат бирүдән баш тарту өчен нигез булып гаризаның әлеге тәртипнең 8 пунктында билгеләнгән таләпләргә туры килмәве тора. Җир асты байлыклары турында геологик мәгълүмат бирүдән баш тарту өчен нигез булган сәбәпләрне бетергәннән соң гариза бирүче вәкаләтле органга гариза белән кабат мөрәҗәгать итәргә хокуклы.

11. Физик һәм юридик затлар үзләренә бирелгән җир асты байлыклары турында геологик мәгълүматны вәкаләтле орган рөхсәтеннән башка өченче затларга бирергә хокуксыз.

12. Гариза бирүченең җир асты байлыклары турында геологик мәгълүматны алуын тәэмин итү түбәндәге документларны биргәндә гамәлгә ашырыла:

1) гариза бирүченең шәхесен таныклаучы документны (гариза бирүче физик зат булганда);

2) затның гариза бирүче исеменнән эш итү вәкаләтләрен раслый торган документны (документны (гариза бирүче юридик зат яисә физик затның вәкиле булганда).

13. Җир асты байлыклары турында геологик мәгълүмат биргән өчен акча алынмый.

---